ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 139-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Н.Н. Хаҗипов, Л.Р. Кадермәтова тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 139-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 501-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
А.К. Хамаев,
Н.Н. Хаҗипов,
Л.Р. Кадерматова
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 75 (I өлеш); № 85 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:
а) 2 пунктчада «өчен» сүзеннән соң «җирләрне резервлау,» сүзләрен өстәргә;
б) 3 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 9 статьяның 3 пунктында «җитештерүен алып бару» сүзләрен «җитештерүе» сүзенә алмаштырырга;

3) 14 статьяның 3 пунктында «Сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары төзү» сүзләрен «Сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары барлыкка китерүче гидротехник корылмалар төзү, шулай ук сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

4) 15 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Запас җирләрдән файдалану Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{37}$ статьясында каралган максатлар өчен сервитут, шулай ук гавами сервитут шартларында рөхсәт ителә.»;

5) 25 статьяның 3 пунктында:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирләрне саклау максатларында җир кишәрлекләре хокукына ия булучылар, гавами сервитутка ия булучылар түбәндәге чараларны үткәрергә тиеш:»;

б) түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) инвазив (чит) үсемлекләрнең куркыныч төрләре таралудан җирләрне саклау һәм мондый үсемлекләрне юкка чыгару.»;

6) $35^{1}$ статьяда:

а) 2 пунктта татарча текст үзгәрешсез кала;

б) 3 пунктта «алып бару» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 44 статьяның 2 пунктында татарча текст үзгәрешсез кала.

**2 статья**

«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы тугызынчы абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 1 – 2; 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш); 2025, № 29 (I өлеш), «корткыч организмнарга каршы көрәшү өчен» сүзләрен «чүп үләннәр һәм зарарлы организмнар, шул исәптән куркыныч инвазив (чит) үсемлекләрнең куркыныч төрләре таралуын булдырмау һәм аларны юкка чыгару өчен» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә:

**3 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 86 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 47 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 75 (I өлеш), № 85 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:

а) 1 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле яңа кырык дүртенче абзац өстәргә:

«гидрометеорология һәм аның белән бәйле өлкәләрдә федераль башкарма хакимият органының территориаль органы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан федераль дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органының территориаль органы белән килештереп, уңайсыз метеорология шартлары вакытларында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны җайга салу чараларын үткәрү тәртибен билгеләү;»;

түбәндәге эчтәлекле кырык бишенче – кырык җиденче абзацлар өстәргә:

«уңайсыз метеорология шартларын гомуми фаразлауны алганда хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлек объектларында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны киметү чараларын үткәрергә тиешле юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга мәгълүмат җиткерү тәртибен билгеләү;

федераль законнарда каралган очраклардан тыш, карантин объектларына һәм чүп үләннәренә кертелмәгән, аларга карата аларны ачыклау, аларның таралуын булдырмау һәм аларны юкка чыгару чаралары күрелергә тиешле инвазив (чит) үсемлекләрнең куркыныч төрләре исемлеген билгеләү;

карантин объектларына кертелмәгән һәм региональ һәм җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрендә аларга карата аларны ачыклау, аларның таралуын булдырмау һәм аларны юкка чыгару чаралары күрелергә тиешле инвазив (чит) үсемлекләрнең куркыныч төрләре исемлеген билгеләү;»;

кырык дүртенче абзацны кырык сигезенче абзац итеп санарга;

б) 2 өлештә «кырык дүртенче» сүзләрен «кырык сигезенче» сүзләренә алмаштырырга;

2) 38 статьяның 1 өлешендә «документ» сүзен «электрон рәвештәге документ (дәүләт экология экспертизасын үткәрү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) документация дәүләт серен тәшкил итә торган һәм (яисә) тарату чикләнгән хезмәт мәгълүматына караган мәгълүматларны үз эченә алган очраклардан тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 89 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**4 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты түбәндәге федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде:

«Гидрометеорология хезмәте турында» Федераль законга һәм «Атмосфера һавасын саклау турында» Федераль законның 1 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 548-ФЗ номерлы;

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 294-ФЗ номерлы;

«Россия Федерациясе Урман кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 29 сентябрендәге 363-ФЗ номерлы;

«Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 31 июлендәге 295-ФЗ номерлы;

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә, алар җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен, җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларның һәм гавами сервитутка ия булучыларның бурычларын төгәлләштерүне, шулай ук Татарстан Республикасы Җир кодексына запас җирләрдән файдалану мәсьәләләрен җайга салуга юнәлдерелгән яңа нигезләмә өстәүне күздә тота.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Җир кодексының сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары төзү максатларында җирләрне резервлау турында нигезләмәсенә төзәтмә кертү, шулай ук редакцион төгәлләштерүләр кертү каралган.

Татарстан Республикасы Экология кодексына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләрен түбәндәгеләр буенча тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә:

гидрометеорология һәм аның белән бәйле өлкәләрдә федераль башкарма хакимият органының территориаль органы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан федераль дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органының территориаль органы белән килештереп, уңайсыз метеорология шартлары вакытларында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны җайга салу чараларын үткәрү тәртибен билгеләү;

уңайсыз метеорология шартларын гомуми фаразлауны алганда хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлек объектларында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны киметү чараларын үткәрергә тиешле юридик затларга,

индивидуаль эшкуарларга мәгълүмат җиткерү тәртибен билгеләү;

федераль законнарда каралган очраклардан тыш, карантин объектларына һәм чүп үләннәренә кертелмәгән, аларга карата аларны ачыклау, аларның таралуын булдырмау һәм аларны юкка чыгару чаралары күрелергә тиешле инвазив (чит) үсемлекләрнең куркыныч төрләре исемлеген билгеләү;

карантин объектларына кертелмәгән һәм региональ һәм җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрендә аларга карата аларны ачыклау, аларның таралуын булдырмау һәм аларны юкка чыгару чаралары күрелергә тиешле инвазив (чит) үсемлекләрнең куркыныч төрләре исемлеген билгеләү.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Экология кодексында дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе булып электрон рәвештәге документ (дәүләт экология экспертизасын үткәрү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) документация дәүләт серен тәшкил итә торган һәм (яисә) тарату чикләнгән хезмәт мәгълүматына караган мәгълүматларны үз эченә алган очраклардан тыш) дип билгеләү тәкъдим ителә.

Шулай ук закон проектында «Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законының төшенчәләр аппаратында булган «пестицидлар» төшенчәсенә төзәтмә кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларына үзгәрешләр кертү таләп ителәчәк:

«Мешинский» региональ әһәмияттәге дәүләт табигать зоология (аучылык) заказнигы турында» 2004 елның 29 гыйнварындагы 41 номерлы;

«Әгерҗе», «Биләр», «Сурнар» региональ әһәмияттәге дәүләт табигать зоология (аучылык) заказниклары турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2004 елның 17 ноябрендәге 494 номерлы;

«Свияжск» региональ әһәмияттәге комплекс профиле дәүләт табигать заказнигы турында нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 14 гыйнварындагы 1 номерлы;

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы;

«Татарстан Республикасы халкының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү концепциясен раслау турында» 2006 елның 30 мартындагы 136 номерлы;

«2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы җитештерү көчләрен кластер ысулы нигезендә үстерү һәм урнаштыру программасын раслау турында» 2008 елның 22 октябрендәге 763 номерлы;

«Татарстан Республикасында уңайсыз метеорология шартлары вакытларында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны җайлау эшләрен оештыру турында» 2012 елның 22 маендагы 407 номерлы;

«Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыгына мөлкәти ярдәм инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 елның 27 августындагы 616 номерлы;

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренең яисә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренең, аларны сату торглар үткәрмичә башкарыла, бәясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 елның 11 июнендәге 432 номерлы.

Моннан тыш түбәндәге норматив хокукый актларны кабул итү таләп ителә:

гидрометеорология һәм аның белән бәйле өлкәләрдә федераль башкарма хакимият органының территориаль органы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан федераль дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органының территориаль органы белән килештереп, уңайсыз метеорология шартлары вакытларында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны җайга салу чараларын үткәрү тәртибе;

уңайсыз метеорология шартларын гомуми фаразлауны алганда хуҗалык һәм

(яисә) башка эшчәнлек объектларында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны киметү чараларын үткәрергә тиешле юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга мәгълүмат җиткерү тәртибе.

федераль законнарда каралган очраклардан тыш, карантин объектларына һәм чүп үләннәренә кертелмәгән, аларга карата аларны ачыклау, аларның таралуын булдырмау һәм аларны юкка чыгару чаралары күрелергә тиешле инвазив (чит) үсемлекләрнең куркыныч төрләре исемлеге;

карантин объектларына кертелмәгән һәм региональ һәм җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрендә аларга карата аларны ачыклау, аларның таралуын булдырмау һәм аларны юкка чыгару чаралары күрелергә тиешле инвазив (чит) үсемлекләрнең куркыныч төрләре исемлеге.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанслауны таләп итми.